**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**12 ноябрь, 2021 ел** **№ 120**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесен билгеләп кую турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34, 37, 85 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУсе җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатураларны карап, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУсе җитәкчесе итеп Хисамутдинов Равил Фәрит улын 2021 елның 15 ноябреннән билгеләп куярга.
2. Биектау муниципаль районы башлыгы урынбасарына «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУсе җитәкчесе белән Контракт төзергә.
3. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаруны тапшыру турында» Биектау муниципаль районы Советының 2021 елның 9 октябрендәге 112 номерлы карарын 2021 елның 14 ноябреннән үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны «Биектау хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru урнаштырырга.

Совет рәисенең урынбасары,
муниципаль район башлыгы урынбасары Ә.Ш.Шакиров